**ГЛАВА**
**Новоишлинского**
**сельского поселения**
**Дрожжановского муниципального**
**района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Чүпрәле муниципаль районы**
**Яңа Ишле**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**422475, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Новые Ишли, ул. Советская, д.24**
**тел. (84375) 30-6-24, факс. 30-6-25**
**E-Mail: Nish.Drz@tatar.ru**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь 2021 ел № 7

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлегенең Яңа Ишле торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст. нигезендә, ст.35 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән расланган,
Яңа Ишле авыл җирлеге Советының 2019 елның 7 октябрендәге 49/1 номерлы карары (2019 елның 15 ноябрендәге 51/5 номерлы редакциясендә) белән расланган
КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлегенең Яңа Ишле торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 1 декабренә 10:30 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Яңа Ишле авылы, Совет урамы, 24 нче йорт, Яңа Ишле авыл мәдәният йорты.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Ишле авыл җирлегенең Яңа Ишле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә акча кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме?:

- Яңа Ишле авылының Төньяк урамы буенча юл-урам челтәрен ремонтлау;
- Яңа Ишле авылының Кооператив, Совет Колхозы урамнарындагы юлларга вак таш салу;

- Яңа Ишле һәм Иске Чүпрәле авыллары арасындагы Пакерлы елгасы аша күпер ремонтлау

«ӘЙЕ» « КАРШЫ»».

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгы: Р.У.Мухаметзянов